Кукмара муниципаль районы
Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«18» август, 2023 ел № 15

**Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Зур Кукмара авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ

:

1. 2023 елның 29 августына 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске-Йорт авылының Үзәк урамындагы 23 нче йорт адресында авыл клубы янында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

8 нче пункт белән тулыландырырга:

«8. Янгын гидрантларын һәм комплектлау материалларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Хәнәфиев